КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 октябрь г.Казань № 986

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 сентябрь, 812 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карар 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына) Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә

барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин